БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
«27» 03 2025 ел

**КАРАР**
№ 121

Балтач муниципаль районы һәм аның составына кергән авыл җирлекләре территориясендә яшәүче гражданнар өчен гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2025 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, Татарстан Республикасының 2015 елның 16 мартындагы «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 13-ТРЗ номерлы Законы, һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү методикасы, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2025 елның 01 февралендәге «Торак урынының бер квадрат метрының уртача базар бәясен куллану турында» 40 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2025 елда салым салынырга тиешле мөлкәт хакының түбәндәге максималь күләмнәрен билгеләргә.

1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен – 571 842 сум;
1.2. Ике кешелек гаилә өчен – 1 143 684 сум;
1.3. Өч кешедән торган гаилә өчен – 1 715 526 сум;
1.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен – 2 287 368 сум;
1.5. Биш кешелек гаилә өчен – 2 859 210 сум;
1.6. Алты кешедән торган гаилә өчен – 3 431 052 сум;
1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен – 4 002 894 сум;
1.8. Сигез кешелек гаилә өчен – 4 574 736 сум.

1.2. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керем күләменең максималь кыйммәте 28165,56 сум тәшкил итә.

2. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2026 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен кабул итүгә кадәр, гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында аз керемле дип тану өчен җаваплы вазыйфаи затларга (хезмәткәрләргә), гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм әлеге карар белән билгеләнгән салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен кулланырга.

3. Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитетының 2024 елның 14 мартындагы «Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2024 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү турында»гы 105 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Балтач район
башкарма комитеты
җитәкчесе

А.Ф.Хәйретдинов

Балтач район башкарма комитетының
2025 елның «27» 03
121 номерлы карарына кушымта

2025 елга һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең, гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү МЕТОДИКАСЫ

1. Найм шартнамәләре буенча торак урыннары бирү нормасы буенча торак урыннары алуның базар бәясен исәпләү күрсәткече (алга таба - исәплщъ күрсәткече) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

СЖ = НП х РС х РЦ,

биредә:

СЖ - исәпләү күрсәткече;

НП - муниципаль берәмлектә гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;

РС - гаилә әгъзалары саны;

РЦ - әлеге муниципаль берәмлекнең һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин ителешнең уртача шартларына туры килә торган, Татарстан Республикасында торак урын сатып алуга түләүсез субсидияләр исәпләү өчен тиешле федераль башкарма хакимият органы билгеләгән гомуми мәйданның бер квадрат метрының уртача базар бәясеннән артмаган торак урын мәйданының бер квадрат метрының уртача исәпләнгән базар бәясе (Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитетының 2025 елның 27 февралендәге 95 номерлы карары нигезендә 31769 сум тәшкил итә).

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

СЖ = 31769 х 18 = 571842 сум

б) ике кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 31769 х 36 = 1 143 684 сум

в) өч кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 31769 х 54 = 1 715 526 сум

г) дүрт кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 31769 х 72= 2 287 368 сум

д) биш кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 31769 х 90 = 2 859 210 сум

е) алты кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 31769 х 108 =3 431 052 сум

ж) җиде кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 31769 х 126 = 4 002 894 сум

з) сигез кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 31769 х 144 = 4 574 736 сум

2. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме СЖ исәпләү күрсәткеченә тигез дип кабул ителә.

Гражданның гаиләдәге һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме түбәндәгечә билгеләнә:

1) торак урын сатып алу өчен ипотека кредиты алу мөмкинлеге булган шәһәрләрдә - СЖ исәпләү бәясе буенча торак урын алуга агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле булган, һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем дәрәҗәсеннән чыгып, түбәндәге формула буенча билгеләнә:

**ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1 - (1 + ПС) - $^{КП}$) / (0,25 х РС)**

торак урын алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме;

СЖ - исәпләү күрсәткече;

ПС - кредит буенча бер ай эчендә процент ставкасы (унарлы вакланма),

(Россия Федерациясе Үзәк Банкы ставкасы 2025 елның 21 февралена еллык 21 %, ягъни аена 21/100/12 = 0,0175 ).

КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны)

(Россия Федерациясе Үзәк Банкы мәгълүматлары буенча, 2025 елның 1 январена уртача үлчәнгән срок - 303,6 ай);

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасы белән фатир бәясенең чагыштырмасы;

0,25 - кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык җыелма кереме белән чагыштырмасы.

## Шәхси торак йортларда яшәүче гражданнар өчен гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен исәпләү

| НП - торак урынның нормасы (кв. м) | СЖ - торак урын сатып алуның базар бәясе (СЖ = РС х РЦ х НП) (сум) | РС - гаилә әгъзалары саны (кеше) | РЦ - торак урынның 1 квадрат метрының базар бәясе (сум) | ПС - кредит буенча айлык процент ставкасы, % | КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (ай) | Кредит суммасы белән фатир бәясенең чагыштырмасы | Кредит буенча түләүнең айлык җыелма керем белән чагыштырмасы | ПД - керемнең максималь күрсәткече (сум). (1 кешегә) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | |
| | | | 31769 | 21/100/12= 0,0175 | 303,6 | 0,7 | 0,25 | |
| 18 | 571842 | 1 | 31769 | 0,0175 | 303,6 | 0,7 | 0,25 | 28165,56 |
| 36 | 994896 | 2 | 31769 | 0,0175 | 303,6 | 0,7 | 0,5 | 28165,56 |
| 54 | 1492344 | 3 | 31769 | 0,0175 | 303,6 | 0,7 | 0,75 | 28165,56 |
| 72 | 1989792 | 4 | 31769 | 0,0175 | 303,6 | 0,7 | 1 | 28165,56 |
| 90 | 2487240 | 5 | 31769 | 0,0175 | 303,6 | 0,7 | 1,25 | 28165,56 |
| 108 | 2984688 | 6 | 31769 | 0,0175 | 303,6 | 0,7 | 1,5 | 28165,56 |
| 126 | 3482136 | 7 | 31769 | 0,0175 | 303,6 | 0,7 | 1,75 | 28165,56 |
| 144 | 3979584 | 8 | 31769 | 0,0175 | 303,6 | 0,7 | 2 | 28165,56 |